**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Яна Аксубай авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

2019 елнын 15 ноябре № 112

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 111 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яна Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставынга мәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Яна Аксубай авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яна Аксубай авыл җирлеге Советының 2019 елның 5 ноябрендәге № 111 номеры белән расланган карарның 3.19 пунктын түбәндәге өстәмә белән тулыландырырга «әгәр граждан җитди сәбәпләр аркасында (сәламәтлеге, инвалидлыгы һ. б. буенча) җыенда катнаша алмаса, аның шәхси гаризасы нигезендә, аның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме , яшәү урыны адресы, аның гражданнар җыенында катнаша алмавының сәбәбе, шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте гражданнар Җыенының йомгаклау тавышларын санаганда исәпкә алына».
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә. Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Яна Аксубай авыл җирлеге башлыгы: М. М. Сөләйманкин